| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУЛАНГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2025 год № 77

Колаңгы тимер юл ст. пос.

«Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы Колаңгы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 2015 елның 12октябрендәге 8 номерлы Колаңгы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяда:

- 2 пунктта «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

- 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата 0,3 %, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләренә;»;

- түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«8) автомәктәпләр полигоннары һәм автодромнары белән мәшгуль җир кишәрлекләренә карата 0,7 %;»;

1.2. 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. Салым ташламалары

1. Җир салымын түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

1) муниципаль казна, бюджет учреждениеләре, гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата (урманнар, урман парклары, парклар, скверлар, шосселар, проспектлар, урамнар, тыкрыклар, мәйданчыклар, тукталышлар, һәйкәлләр, колонкалар, су объектлары, су башнялары, чишмәләр, коелар, артезиан скважиналары, канализация-насос станцияләре, гидротехник корылмалары астында);

2) муниципаль казна, бюджет учреждениеләре, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә, зиратлар, үләт базлары һәм граждан күмүләре, янгын деполары, карьерлар биләгән җир кишәрлекләренә карата;

3) чистарту корылмалары биләгән җир кишәрлекләренә карата физик һәм юридик затлар;

4) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация узган муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыкларының идарәче компанияләре;

5) физик затлар - янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләре һәм әлеге статусны раслый торган документы булган ирекле янгын сүндерүчеләр;

6) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә (алга таба - мобилизация буенча чакырылган гражданнар) чакырылган гражданнар һәм аларның гаиләләре әгъзалары (ире, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балалары) Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары;

7) алар белән бергә яшәүче мобилизация буенча чакырылган гражданнарның ата-аналары (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән);

8) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзалары (ире, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);

9) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләренең алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) ата-аналары.

Физик затларга ташламалар эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган салым түләүчене сайлау буенча бер җир кишәрлегенә карата бирелә дип билгеләргә.

Физик затның салым ташламасына хокукын раслаучы документлар салым түләүче буларак салым органына үз сайлавы буенча тапшырыла.

Әлеге пунктның "6", "7", "8", "9" пунктчалары нигезендә салым ташламасына хокуклы гражданнар исемлеге Колаңгы авыл җирлеге башкарма комитеты салым органына тапшырыла.».

2. «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы Колаңгы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 14 ноябрендәге 72 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

http://kulangin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Колаңгы авыл җирлеге Башлыгы Ф.Т.Нигъмәтҗанов